КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 16 апрель г.Казань № 293

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль әһәмияткә ия проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган Татарстан Республикасы оешмаларына дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2009 ел, 8 июнь, 373 нче карары белән расланган Социаль әһәмияткә ия булган проектларны тормышка ашыруда катнашучы коммерциягә карамаган оешмалар өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты грантларын алуга республика конкурсы турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасындагы социаль әһәмияткә ия проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2009 ел, 8 июнь, 373 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 28 декабрь, 890 нчы; 2010 ел 21 сентябрь, 749 нчы; 2011 ел, 29 июль, 606 нчы; 2012 ел, 9 июнь, 500 нче; 2013 ел, 28 июнь, 444 нче; 2014 ел, 5 июнь, 380 нче; 2014 ел, 8 октябрь, 734 нче; 2014 ел, 18 октябрь, 769 нчы; 2015 ел, 21 сентябрь, 693 нче; 2015 ел, 2 ноябрь, 830 нчы; 2016 ел, 14 гыйнвар, 8 нче; 2016 ел, 3 ноябрь, 812 нче; 2017 ел, 13 июнь, 374 нче; 2018 ел, 19 февраль, 93 нче; 2018 ел, 21 апрель, 277 нче; 2019 ел, 27 февраль, 135 нче, 2019 ел, 30 июль, 633 нче, 2020 ел, 06 март, 174 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Социаль әһәмияткә ия булган проектларны тормышка ашыруда катнашучы коммерциягә карамаган оешмалар өчен Татарстан Республикасы Министрлар

Кабинеты грантларын алуга республика конкурсы турында нигезләмәгә, IX бүлекнең 9.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«9.1. Конкурс комиссиясе түбәндәге вәкаләтләрне башкара:

агымдагы елның 1 июленә кадәр:

Конкурсны үткәрү вакыты турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдимнәр кертә;

коммерцияле булмаган оешмалар, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тәкъдимнәре нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Конкурс номинацияләре исемлеген билгеләү турында тәкъдимнәр кертә;

агымдагы елның 1 августына кадәр һәр номинация буенча экспертлар исемлеген формалаштыра һәм раслый, Конкурс үткәрү буенча чыгымнар сметасын раслый, шул исәптән экспертлар хезмәтләре өчен түләүгә дә;

агымдагы елның 1 октябренә кадәр Конкурста җиңүчеләрне билгели.».

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин